**ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ, СЫЗЫП АК НУР белән...**

# ЯШЬ КАЛӘМЧЕ

**Сентябрь, 2024ел**




**Бар күңеллелек дөньяда, бар бер ямь бүген,**
**Нәрсәдән бу? Мин беләм:бәйрәм бүген, бәйрәм бүген.**
**Г.Тукай**

## 2 сентябрь- белем бәйрәме

***Кадерле укучылар! Сезне Белем көне белән котлыйбыз! Бу уку елы сезнең өчен кызыклы һәм уңышлы булсын. Тырышып укыгыз һәм белемнең зур байлык икәнен онытмагыз!***

***Кадерле укытучылар! Сезне Белем бәйрәме белән чын күңелдән котлыйбыз! Хезмәтегез һәм белем таратуга керткән өлешегез өчен сезгә чиксез рәхмәт. Сезнең тырышлыгыгыз үзенең татлы җимешләрен китерсен, укучыларыгызһәрвакыт шатландырып торсын, яңадан-яңа уңышларга ирешергә рухландырсын!***

Син атлаган юлларга
Алтын яфрак сибелә.
Чыңлый көмеш кыңгырау,
Дәшеп белем иленә.

Бик күп нәрсә белерсең син
Туган илең турында.
Син бит хәзер бик зур кеше –
Әлифбаң бар кулыңда.

Белем көне белән, дустым,
Омтыл һәр көн белемгә!
Җиһанның бар төсмерләре
Чагыла уку-гыйлемдә

Изге телнең моңын, бар тылсымын;
Җир йөзендәниләр барлыгын.
Ни өчен кич кояш батуын,
Якты йолдызларның балкуын.
Диңгез, океаннарны, күлләрне;
Иксез-чиксез галәм серләрен.
Агач, үсемлекләрне, гөлләрне;
Африканың кайнар чүлләрен.
Җырчы чишмәләрне, җилләрне,
Тагын бик күп әллә ниләрне
Мәктәбебез безгә өйрәтер.



2 сентябрь- белем бәйрәме. Алтын көз аенын беренче көннәре тантана итә. Матур, кояшлы көзге көнгә тагы да ямь өстәп, бәйрәмчә киенгән , кулларына кадерле укытучыларына дип чәчәк бәйләмнәре тоткан балалар , дулкынланган ата-аналар, укытучылар мәктәпләргә җыелдылар.

Безнең мәктәп ишегалдында да зур бәйрәм тантаналары булды.Җыр-бию тавышлары яңгырап торды. Мәктәп дирекциясе алдынгы укучыларны бүләкләде.

Шулай итеп, яңа уку елы башланып китте. Барлык укучыларга да, укытучы апа-абыйларыбызга да уңышлар телибез!

## Бәйрәм тантанасыннан күренешләр








**5 нчеләр урта звенога күчтеләр.Аларга уңышлар телибез.**
**1 нче сыйныф сәгате**



**Бәйрәм уңаеннан, аның тарихы һәм үзенчәлекләре белән танышып китик әле.**

1 сентябрь – ата-аналар һәм балалар өчен иң мөһим көннәрнең берсе. Кемдер бу көнне түземсезлек белән көтә, ә кемдер җәй беткәнгә моңсулана. Бөтенроссия Белем көне – иң кечкенә укучылар - беренче сыйныфлар өчен олы бәйрәм.

Бәйрәмнең барлыкка килүен рәсми рәвештә 1984 елдан исәплиләр. Әмма бәйрәм үзе 1930 елда мәҗбүри белем бирү турындагы законны кабул итү белән үк барлыкка килгән. Моңа кадәр уку елы башлануның катгый датасы булмаган. Россия империясе вакытында шәһәр укучылары август ахырында, сентябрь башында, ә авыл укучылары 1 декабрьдә укуга керешкәннәр, чөнки авыл балалары барлык кыр эшләре тәмамлангач кына, мәктәпкә йөри алган.

1984 елның 1 сентябренә кадәр барлык мәктәпләрдә дә тантаналы линейкалар, аннан соң «Тынычлык дәресе» һәм башка дәресләр үткәрелгән, ягъни бу бер тулы уку көне булган. Ә хәзер исә 1 сентябрь бары тик тантаналы рәвештә генә уза, барлык укучылар да чәчәк бәйләмнәре белән, мәктәп формасыннан килә. Тантананың төп мизгеле – беренче кыңгырау. Кыңгырау чыңы яңа уку елы башлануны билгели.



## “Яшь каләмче”түгәрәге